

Саранск шәһәренен Мордовия дәvләт милли драма театрында «Бердәм Россия хатын-кызлары хәрәкәте» проекты активистлары Мордовия Республикасында яшәvче хатын-кызларны Әниләр коне белән котладылар.

Әниләр коне, могаен, барлык булган бәйрәмнәр арасында ин кvнеллеседер. Ноябрьнен һәр сонгы якшәмбесендә Россиядә Әниләр коне билгеләп vтелә, ул аналарнын чиксез мәхәббәтен, хезмәт союҹәнлеген, кайгыртучанлыгын, сабырлыгын һәм фидакарьлеген чагылдыра. Һади Такташыбыз сvзләре белән әйткәндә:
«Ана - боек исем!
Нәрсә житә ана булуга?!
Хатыннарнын ботен матурлыгы,
Ботен кvрке - ана булуда! »
Бу конне махсус операциядә катнашучыларнын кvп балалы әниләренә, әни-ләргә һәм хатыннарга - «Мордовия хатын-кызлары берлеге» активына бvләкләрне Мордовия Республикасы социаль яклау, хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итv министры урынбасары Светлана Шувалова белән «Россия хатын-кызлар берлеге»нен тобәк бvлеге рәисе Ольга Игнатова тапшырды. Алар хатын-кызларны якты бәйрәмнәре белән котладылар. Мордовиядә яшәvче хатын-кызларнын югары хезмәтләрен билгеләп vттеләр.
Әлеге чарада, башкалар белән беррәттән, «Чулпан» Мордовия Республикасы татар хатын-кызлары ижтимагый оешмасыннан оч ана катнашты. Россия хатын-кызлар берлегенен Мактау грамотасы белән СВОда хәбәрсез югалган улынын әнисе Наилә Шамиль кызы Каримова бvләкләнде.



Мордовия хатын-кызлар берлегенен Мактау грамотасы Рима Фатих кызы Байгельдинага тапшырылды. Ул әнгәмәсендә:
- Торле-торле чараларда катнашып киләм, ә бvгенгесе тослесендә беренче тапкыр. Беренче тапкыр әни буларак бvләкләнәм дә. Бу минем кvнелемә бик тә хуш килде, чонки әни исемен йортv – горурлык.
Татарлар тормышында актив эш алып барган очен Мордовия Республикасы татар хатын-кызларынын «Чулпан» ижтимагый оешмасы исеменнән бирелдә мин. Белгәнегезчә, татар милли киемнәрен тегәм, бизим, кvргәзмәләр оештырам. Ижтимагый (общественная) эштә актив булу баланны тәрбияләvдә, гаилән очен зур плюс, чонки киләчәк буын беренче чиратта гаиләдә, әти-әни vрнәгендә тәрбияләнә. Ә бvләкләнv – гаилә очен, кvнелен очен тагын бер баскычка vрмәләv.
Ләмберә районы Татар Тавла авылында хормәт казанган, гомеренен кvп елларын

якташлары балаларына туган татар теле һәм татар әдәбиятын укыткан, лаеклы балалар тәрбияләгән, Татар Тавла хатын-кызлары Советын житәкләгән Тәнзилә Юсиф кызы Секаева да Аналар конөнә багышланган бәйрәмдә катнашты.
Чарада Мордовия хатын-кызлар берлегенен Мактау грамотасы белән Сабина Таһир кызы Гуданец та бүләкләнде. Сабина Таһир кызы СВОда катнашучылар очен гуманитар ярдәм жыя һәм гуманитарканы илтеп тә бирә.
Ләмберә районы «Ләмберә балалар ижаты йорты» («Лямбирский Дом детского творчества») директоры Гюзель Шамиль кызы Алукаева һәм башка татар хатын-кызлары бу бәйрәмдә кот-лаулар кабул иттеләр.
Бәйрәм кунаклары Мордовия милли драма театры мәйданчыкларында оештырылган мастер-классларда катнаша алдылар. Тантаналы олеш тәмамланганнан сон, кунаклар рәхәтләнеп бәйрәм концертын карадылар.

**Наилә НАСЫРОВА**